РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 6 2022 елның 4 феврале

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 72 номерлы карары белән расланган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248–ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 72 номерлы «Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- декарарга кушымтаның 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3 Индикатив күрсәткечләр:

1) хисап чорында үткәрелгән планлы контроль чаралар саны;

2) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш контроль чаралар саны;

3) хисап чорында контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килү-килмәүне ачыклау яисә контроль объектының мондый параметрлардан читләшүе нигезендә үткәрелгән планнан тыш контроль чаралар саны;

4) хисап чорында үткәрелгән хезмәттәшлек белән контроль чараларның гомуми саны;

5) хисап чорында үткәрелгән ККЧның һәр төре буенча үзара хезмәттәшлек итү белән контроль чаралар саны;

6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль чаралар саны;

7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

8) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;

9) хисап чорында аларның нәтиҗәсе буенча мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль чаралар саны;

10) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль чаралар саны;

11) хисап чорында контроль чаралар нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

12) хисап чорында контроль чаралар үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) хисап чорында алар буенча прокуратура органнары тарафыннан килештерүдән баш тарткан контроль чаралар үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;

15) хисап чоры ахырына һәр хәвеф-хәтәр категориясе буенча хәвеф-хәтәр категориясенә кертелгән исәпкә алынган контроль объектлары саны;

16) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затларның саны;

17) хисап чорында аларга карата контроль чаралар үткәрелгән исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

18) хисап чорында аларга карата контроль органы тарафыннан карау срогы бозылган шикаятьләр саны;

19) хисап чорында суд тәртибендә контрольдә тотылучы затлар тарафыннан җибәрелгән контроль органнарының вазыйфаи затларының карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмавын) дәгъвалау турында дәгъва гаризалары саны;

20) хисап чорында алар буенча игълан ителгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән, суд тәртибендә контрольдә тотылучы затлар тарафыннан җибәрелгән контроль органнарының вазыйфаи затларының карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмавын) дәгъвалау турында дәгъва гаризалары саны;

21) хисап чорында муниципаль контрольне (күзәтчелекне) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозу белән үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль чаралар саны.»;

2. карарны түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт белән тулыландырырга:

«2.1. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәнең 6 бүлегендәге нигезләмәләр 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

А.В.Умников